ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладлары хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына яшьләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагыла торган законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә ярдәм итү кирәклегенә аеруча игътибар итеп, дәүләт яшьләр сәясәтен яшьләр мәнфәгатьләрендә үстерү һәм гамәлгә ашыру өчен шартларны камилләштерү чараларын күрергә.

3.2. «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законын ел саен финанслауны яңарту мәсьәләсен карарга.

4. Республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладында булган тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2472-VI ДС